Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы

карары

2022 елның 13 ноябре №122

«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 24 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник поселогы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

1. Юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

2. Жилой Рудник урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

3. Жилой Рудник авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү.

4. Урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.

5. Урамнарга асфальт салу, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

6. Янгын гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү

7. Жилой Рудник авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев